елда җиде сыйныфны тәмамлагач, фермага бозау караучы булып басуга алып чыгып куям, мин китүгә үк ятып йоклыйлар. Алар да, мин нәгә эшкә чыгып киттем. 34 ел сәүдә системасында бухгалтер булып эшлә- хөрмәтендә яшәргә насыйп булсын.

# Бердәм булсак кына

**очрашу**

**9 декабрь – халыкара коррупциягә каршы көрәш көне буларак 2003 елда игълан ителә.**

Фәридә ФИЛАТОВА

Нәкъ шул вакытта Берләшкән Милләтләр оешмасы генераль ассамблеясенең коррупциягә каршы көрәш буенча конвенциясенә кул кую ачык дип белдерелә. Әлеге документ аңа кул куйган илләрдә ришвәт, бюджет акчаларын урлау, ришвәтчелек нәтиҗәсендә алынган акчаларны юуны җинаять җаваплылыгына тартуны күздә тота. Конвенция положениеләренең берсендә, ришвәтчелек нәтиҗәсендә алынган акчаны шул илгә кире тапшыру тиеш, диелгән. Россия исә беренчеләрдән булып әлеге документка кул куя.



Шушы уңайдан Олы Әтнә урта мәктәбенең югары сыйныф укучылары каршында район прокуроры урынбасары Газизов Марат Ислам улы чыгыш ясады. Үзенең чыгышында хокук органнары вәкиле коррупциягә каршы көрәшнең бүгенге көндә зур әһәмияткә ия булуына басым ясады. «Безнең илдә коррупциягә каршы көрәш киң колач алды. Закон чыгаручы органнар тарафыннан әлеге заман афәтенә каршы төрле законнар кабул ителеп тора. Әмма кызганычка каршы, әлегә аны җиңү мөмкин түгел. Моның өчен барыбыз да бердәм булып көрәшергә кирәк», – диде ул.

Соңгы вакытта ришвәтчелек буенча закон бозулар арасында чиновникларның эшмәкәрләргә законсыз акчалата ярдәм хисабына "канат астына алу"лары киң таралган. Югары дәрәҗәле затларның ришвәтчелек эшчәнлеген документлаштыру бик четерекле һәм зур хезмәт сорый торган эш. Икътисади җинаятьләрнең бу төрен тикшерүдә һәм судка китереп җиткерү бик катлаулы эш.

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!**
**ТӨРЛЕ ТӨБӘКТӘ ЯШӘҮЧЕ ЯКТАШЛАРЫБЫЗ!**
Районда узган чаралардан фото һәм видеорепортажларны, мәкаләләрне тәүлек буе **atnya-rt.ru** сайтына кереп укый һәм карый аласыз.

Мине ул вакытларда Ч
тәбе директоры итеп т
барып утырабыз, анда м
Заһид Шәрәфиевич Гаде
өлешендә иң беренче Ар
ла. Җитәкче андагы дир
1952-1953 елларда ВЛКСМ
кретаре булып эшли. Чы
безгә эләгә: өлгереш – т
Мин яшь кеше, таныш т
белән дә аклана алмыйм.
Шул елларда олы кыз
гә бирдем. Беркөнне без
иң башларымнан кысып
элекке мәгариф бүлеге
кияүнең атасының апас
Шулай итеп кода була ин
Хәзер инде вафат булу
язмам аның рухына дога

**шиг**

## Кышка мәдх

Ап-ак кар кояш нурынд
Күңелләрне иркәли.
Суык борынны чеметә,
Кайтыгыз бар, өйгә, ди
Юк, кайтмыйбыз, текә
Тәгәрәшеп уйныйбыз,
Саф һавада әүмәкләше
Һич кенә дә туймыйбы
Кышка мәдхия җырлы
Кызылтүшләр, чыпчык
Бу манзара тәэсиреннә
Яшәрә карт-карчыклар
И, гүзәл кыш, озаклам
Ак юрганың ачарсың.
Көз яшьләрең түгә-түга
Безне ташлап качарсы

Илсур ШАКИРОВ,
Олы Мәңгәр авылы